# САРМАНАЙ

*Мәфтәдим Гыйләҗев көе*
*Вил Казыйханов шигыре*

Кил әле син Сарманайга,
Көтәрмен юл чатында,
Сиңа бер сүз әйтәсем бар
Тик икебез хакында.

*Кушымта:*
Сарманай, Сарманай,
Юлларында очраштыр,
Аерма безне болай.

Сарманай буйлары таллык
Ярлары яшел чирәм,
Чәчәкләр җәйгән тугайга
Сине сагынып киләм.

*Кушымта.*

Сарманай сулары салкын,
Салкын булса да йөзәм,
Сагынуга чик-чама юк.
Шулай булса да түзәм.

*Кушымта:*
Сарманай, Сарманай,
Юлларында очраштыр,
Аерма безне болай.